ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГУЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГУЛКИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№2**

**КАРАР**
**02.02.2022 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында 27.01.2022 № 57 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Гулкинавыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2022 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" 2021 елның 08 февралендәге 01 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **С.Д.Инькова**

Зәй муниципаль районы
Гулкин авыл җирлеге
башкарма комитетының
«02» февраленнән 2022ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 01 февраленнән
Гулкин авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2649,00 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1132,25 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3183,43 |
| Барысы | 6964,68 |

Зәй муниципаль районы
Гулкин авыл җирлеге
башкарма комитетының
«02» февраленнән 2022ел
2 номерлы карарына
2нче кушымта

## Гулкин авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 726,37 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1976,90 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1105,18 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3156,23 |
| Барысы | 6964,68 |